Ә сез беләсезме?

# ИҢ ЗУР БАЙЛЫК

Рушания ДӘҮЛӘТОВА

"Адәм баласының иң зур байлыгы - тәне вә җаны сәламәт булу. Әмма күп вакыт без бу байлыкның кадерен белмибез. Бөтен дөньяның хуҗасы булсаң да, тәнен сәламәт булмаса, рәхәтлек сизмәссең.

Чирнең сәбәбен белеп, аны китереп чыгаручы нәрсәләрдән сакланырга кирәк. Мәсәлән, тирләп салкынга чыгу, исле (күмер исе, агулы ис) бүлмәдә тору, майлы ризыклар ашау, исерткеч эчемлекләр эчү, әфьюн кабу - болар барысы да чирләүгә китерә.

Тән һәм киемнәрне, урынҗирләрне чиста тоту, тәһарәт алу, госел коену, намаз уку, ураза тоту, өй эчендәге хезмәтләрне башкару-сәламәтлек күнекмәләредер" - ди Риза"ддин Фәхреддин "Нәсыйхәт" дигән хезмәтендә.

Иман. Иманлы булу. Халкыбыз аңына бик борынгыдан сеңгән төшенчәләр бу. Иманлы булу - ул динле булу, дингә табынып яшәү дигән сүз генә түгел, ул әхлакый кагыйдәләр буенча тормыш итүне аңлата. Тикмәгә генә әби-бабайларыбыз безне бөтен начар гадәтләрдән тыеп тормыйлар.

Пөхтә, чиста, матур итеп киенү, сабыр гына сөйләшү, мөлаем, ярдәмчел булу - шундый күркәм сыйфатлар безгә борынборыннан әби-бабаларыбыздан мирас булып калган.

Гомумән, халкыбыз әдәп сакларга, инсафлы, намуслы булырга, ата-ана хакын хакларга, сәламәт яшәү рәвешен алып барырга, борынгы йолаларны мөмкин кадәр үтәргә тырышкан. Кызганычка каршы, бу сыйфатлар өлкән буында гына сакланып калды.

Шуңа күрәдер Ризаэддин Фәхреддин гомере буе тәрбия эшенә зур әһәмият бирә: "Тәрбия-акрынлык вә тәртип белән камиллек булдыру димәктер. Тәрбиясе булмаган җирдә гүзәл ашлык җитешмәгән кебек, тиешле тәрбия бирелмәгәндә гүзәл кеше дә җитешмәс. Шулай икән, тәрбия иң кирәкле бер эш булачактыр", - ди ул.

Галимнең кайсы хезмәтен генә алып карасаң да, аларның һәрберсендә ("Тәрбияле ана", "Тәрбияле хатын", "Шәкертлек әдәбе", "Насыйхәт" һ.б.) тәрбияле кеше башкалардан өстен куелып бирелә, чөнки һәр заманда да тәрбияле кешедән үрнәк алалар, аны мактыйлар, хөрмәт итәләр, ә тәрбиясездән йөз чөерәләр.

Заманаңың бозыклыгын Ризаэддин Фәхреддин кешеләрдә әдәп-әхлак сыйфатларының түбән дәрәҗәдә булуында күргән. Моны бүгенге чынбарлыкка күчерсәк, яшьләрнең әхлакый тәрбиясезлеге сәбәпләренең берсе эшсезлек икәненә хәзер күпләр ышана инде.

Иң куркынычы шул: без матди байлыкны көч кулланмый, тир түкми генә табу юлларын эзлибез. Моңа радио-телевидение тапшырулары да булышлык итә, әлбәттә.

Җәмгыятькә лаеклы алмаш, лаеклы шәхес тәрбияләү мәсьәләсендә Ризаэддин Фәхреддин үзенең бөтен гомере буенча уйлана, борчыла, бу бик мөһим мәсьәләгә берьяклы гына карамыйча, аның кешене бөтен яктан да камил итеп күрәсе килә. Һәркемнең җәмгыятьтә, тормышта үз урынын үзе табарга тиешлеген күрсәтеп, ул кеше рухи, әхлакый тәрбия алу өстенә хезмәт тәрбиясе дә алырга тиеш дип саный. Аның фикеренчә, "...һичбер эш эшләмичә һәм эшләргә дә теләмичә сузылып яту, кул кушырып утыру яки дога кылып намазлык өстендә утыру тормыш, яшәеш берни дә бирми".

Икътисади яктан алга киткән кайсы гына дәүләтне алсак та, анда алгы планга хезмәт тәрбиясенең куелганын күрәбез. Андый тәрбия гаиләдән башлана.

Россиядә ир-атларның гомер озынлыгы - уртача 65 яшь, ә хатын-кызларныкы 71 яшь тирәсе, ди белгечләр. Галимнәр әйтүенчә, кешенең йөрәге якынча 400 ел тибә ала, ә бөере хәтта 800 елга "чыдай" икән. Илдә үлүчеләр саны туучылардан күпкә арта, 2,5 процент бала гына сау-сәламәт булып туа, үсмерләр арасында үз-үзенә кул салу буенча Россия Европада беренче урында тора, 10 мең егет армия хезмәтенә барудан качып йөри, никахка керүчеләр белән аерылышучылар саны бертигез дәрәҗәдә. Күп укучы аз хәрәкәтләнә, спорт белән шөгыльләнми диярлек. Көнозын парта артында, кичен компьютер, телевизор каршында утыра.

Бу уңайдан Ризаэддин Фәхреддингә мөрәҗәгать итү урынлы булыр. "Дөрестән дә, дөнья - бәла вә каза, һәртөрле мәшәкать, кайгы вә хәсрәт мәйданы. Адәм баласының гомере монда күбесенчә авыру белән, ризык вә кирәк әйберләр артыннан йөрү вә йөгерү белән үтә. Арада булган рәхәт заманнар йокламада төш күргән сыман үтә дә китә.

Бөтен хәле вә тарихы шушы рәвештә булган урынга кешенең фикере, күңелле тукталу вә шуңа канәгатьләнү ихтималы юк, һич юк. Адәм баласының кыска гына гомере вә санаулы көннәре шушындый вакыйгалар белән уралу, һәртөрле мәшәкатләр белән чолгану сәбәбеннән берәр төрле юаныч табуга мохтаҗ булуы табигый".

Р.Фәхреддин менә нәрсәләр яза: "Адәм баласына үзенең кем икәнлеген, кайдан килеп кая барачагын, ни өчен яратылып вә дөньяда торуын, бу дөньяда гомер сөргән вакытында йөрергә тиешле булган юлын, үзе өчен нәрсәләр зарарлы вә нинди нәрсәләр файдалы икәнлеген белдерә торган бердәнбер корал-диндер. Кешелек җәмгыятендә гаделсезлек, кыерсыту, изү, золым, азгынлык, үтерүләр бетсен өчен бердәнбер чара - әдәп-әхлакны ныгыту".

Р.Фәхреддин мәгърифәт юлында беренче планга гаилә тәрбиясен куя. Аның фикеренчә, тәрбиянең башы-гаилә, ата белән ана беренче тәрбиячеләр.

Ә дөрес тәрбияне ничек алырга мөмкин соң? Ни рәвешле әти-әни баласын туры юлга бастыра ала? Үзләрен хөрмәт итәргә, картайган көннәрендә дә саклап, карап торырга ничек өйрәтергә була?

Бу сорауларның чишелешен нәкъ Ризаэддин Фәхреддиннең хезмәтләрендә табарга мөмкин: "Дөньяга килгән сәгать белән балалар-тәрбиягә мохтаҗлардыр. Боларны тәрбияләүчеләр дә-аналардыр. Аналар балаларның һәр эшләрен гадәткә салырлар. Тәрбияле аналар-олуглар алдында эшләргә ярамаган эшләрне балалар алдында эшләмәсләр вә сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләмәсләр, моннан бик сакланырлар. Шулай ук балаларның хәйләгә, ялган сөйләргә өйрәнүләренә сәбәп булырдай нәрсәләрне кылмаслар", - дип әйтелә. "Тәрбияле ана" исемле хезмәтендә.

Бөек галим гаиләдәге сәламәт яшәү рәвешенең түбән булуның сәбәпләрен хатын-кыздан эзли. "Яхшы тереклек - гүзәл холык иясе хатыннан башка булмас. Дөньяның бәхетсезләре-тәрбияләре хатын белән баладан булган затлардыр. Адәм балаларының бәхетләре-хатыннар кулында...".

Мондый очракта табигый сорау туа: андый,галим әйткәнчә, гүзәл холыклы хатыннарны кайдан табарга соң? - Гаиләдән, мәктәптән. "Адабе тәгълим" ("Укыту кагыйдәләре") китабының 11нче битендә мәктәптә балаларны тәртипкә, әхлакка өйрәтүче укытучыларның коры сүз белән түгел, ә үзенең шәхси үрнәгендә тәрбияләү осталыгы да булырга тиешлеген таләп итә. Аның фикеренчә"... Хозурына саф-саф булып тезелгән шәкертләргә мактаулы холыкларын дөрес бирүдән элек, вә фигыле белән шәкертләргә күчергән булырга тиештер. Болай булмаганда, шәкертләргә бирелгән нәсыйхәтләр-файдасыз, укытылган дәресләр дә нәтиҗәсез калыр. Чөнки күп вакытта балалар мөгаллимнең сүзенә түгел, аның фигыленә иярерләр. Соңыннан ияргән нәрсәләре аларда бер гадәт булып китәр...".

Бүгенге заман яшьләренең тагын бер бәхетсезлеге галимебез вакытында гаилә кора алмауларында күрә. "Гаилә" хезмәтендә бөек галим һәр ата, һәр ананың, ир һәм хатынның нәрсә өчен җаваплы булу кагыйдәләрен тудырган. "Ир белән хатынның шәригать кушкан суратта бергә кушылуыннан, ягъни җан һәм тән бер булуыннан гаилә төзелә... Бер-берегездән көнләшмәгез, ачуланышмагыз, үпкә тотмагыз, ачу кумагыз, бер-берегезне хөрмәтләгез".

Р.Фәхреддиннең кешеләр язмышын алдан күрә белү сәләтенә сокланмыйча булдыра алмыйсың. Аның әсәрләре дистәләгән буынны илгә, милләткә тугрылыклы булу, хезмәт, матурлык, сөю, игелекле, сәламәт, сәләтле булырга омтылу, киләчәгең турында да уйлап-кайгыртып яшәү рухында, яктылык идеалларында тәрбияли.

Тыйнаклыгы, итагатьле, фикер-карашларының ачыклыгы белән замандашларын ла сокландыра алган Р.Фәхреддиннең бай мирасы 21нче гасыр шәхесен тәрбияләүдә дә ярдәм итә.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Шәүүәл 2014 миләди йыл**
**1435 һижри йыл.**

| Шәүүәл | Аҙна көндәре | Июль Август | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығы | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дүшәмбе | 28 | 4.51 | 6.21 | 14.30 | 20.53 | 22.23 | 23.53 |
| 2 | Шишәмбе | 29 | 4.52 | 6.22 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 3 | Шаршамбы | 30 | 4.54 | 6.24 | 14.30 | 20.49 | 22.19 | 23.49 |
| 4 | Кесе йома | 31 | 4.56 | 6.26 | 14.30 | 20.48 | 22.18 | 23.48 |
| 5 | Йома | 1 | 4.57 | 6.27 | 14.30 | 20.46 | 22.16 | 23.46 |
| 6 | Шәмбе | 2 | 4.59 | 6.29 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 23.44 |
| 7 | Йәкшәмбе | 3 | 5.01 | 6.31 | 14.30 | 20.42 | 22.12 | 23.42 |
| 8 | Дүшәмбе | 4 | 5.03 | 6.33 | 14.30 | 20.40 | 22.10 | 23.40 |
| 9 | Шишәмбе | 5 | 5.04 | 6.34 | 14.30 | 20.38 | 22.08 | 23.38 |
| 10 | Шаршамбы | 6 | 5.06 | 6.36 | 14.30 | 20.36 | 22.06 | 23.36 |
| 11 | Кесе йома | 7 | 5.08 | 6.38 | 14.30 | 20.34 | 22.04 | 23.44 |
| 12 | Йома | 8 | 5.10 | 6.40 | 14.30 | 20.32 | 22.02 | 23.32 |
| 13 | Шәмбе | 9 | 5.12 | 6.42 | 14.30 | 20.30 | 22.00 | 23.30 |
| 14 | Йәкшәмбе | 10 | 5.13 | 6.43 | 14.30 | 20.28 | 21.58 | 23.28 |
| 15 | Дүшәмбе | 11 | 5.15 | 6.45 | 14.30 | 20.26 | 21.56 | 23.26 |
| 16 | Шишәмбе | 12 | 5.17 | 6.47 | 14.30 | 20.23 | 21.53 | 23.23 |
| 17 | Шаршамбы | 13 | 5.19 | 6.49 | 14.30 | 20.21 | 21.51 | 23.21 |
| 18 | Кесе йома | 14 | 5.21 | 6.51 | 14.30 | 20.19 | 21.49 | 23.19 |
| 19 | Йома | 15 | 5.23 | 6.53 | 14.30 | 20.17 | 21.47 | 23.17 |
| 20 | Шәмбе | 16 | 5.24 | 6.54 | 14.30 | 20.15 | 21.45 | 23.15 |
| 21 | Йәкшәмбе | 17 | 5.26 | 6.56 | 14.30 | 20.12 | 21.42 | 23.12 |
| 22 | Дүшәмбе | 18 | 5.28 | 6.58 | 14.30 | 20.10 | 21.40 | 23.10 |
| 23 | Шишәмбе | 19 | 5.30 | 7.00 | 14.30 | 20.08 | 21.38 | 23.08 |
| 24 | Шаршамбы | 20 | 5.32 | 7.02 | 14.30 | 20.05 | 21.35 | 23.05 |
| 25 | Кесе йома | 21 | 5.34 | 7.04 | 14.30 | 20.03 | 21.33 | 23.03 |
| 26 | Йома | 22 | 5.35 | 7.05 | 14.30 | 20.01 | 21.31 | 23.01 |
| 27 | Шәмбе | 23 | 5.37 | 7.07 | 14.30 | 19.58 | 21.28 | 22.58 |
| 28 | Йәкшәмбе | 24 | 5.39 | 7.09 | 14.30 | 19.56 | 21.26 | 22.26 |
| 29 | Дүшәмбе | 25 | 5.51 | 7.11 | 14.30 | 19.54 | 21.24 | 22.54 |
| 30 | Шишәмбе | 26 | 5.43 | 7.13 | 14.30 | 19.51 | 21.21 | 22.51 |

# ДИНЕБЕЗ ТУРЫНДА УЙ - ХИСЛӘРЕМ

Дин кардәшләрем белән динебез турындагы уй-хисләрем белән уртаклашмакчы булдым. Ниятем: динебез турында әз булса да кирәкле мәгълүмат бирергә тырышу. Мөселман кешесенең җан азыгы - ул дини белем алу. Рәсүлебез с.г.в. безгә бишектән алып ләхеткә чаклы белем алырга кушкан. Бүгенге мөселманнарның күпчелеге дини мәгълүмат алуга мохтаҗ. Дини вәгазь - нәсыйхәт ул җан азыгы.

Аның аркылы кешенең иманы ныгый, үсә. Ничек сукыр кеше таягы белән капшап юл эзләгән кебек, без дә, хәзерге мөселманнар, һәрбер дин турында әйтелгән сүзгә ышанып, гореф-гадәтләребезне дә дин дип белеп, чын исламнан бик ерак торган хәлебездә дә, үзебезне юк - бар белән юатып, тиешенчә Аллаһудан курка да белмәгән хәлебездә, "Аллаһ рәхимле, кичерер әле", дип, гомер уздырып, гафләт йокысында кала бирәбез. Шуңа күрә мин, әз булса да, кардәшләрем иманы артса, миңа да савап булыр дип язып утырам. Без, хатын-кызлар, Богырысланда мәчеттә укыйбыз. 20-30 хатын Корьәнне үзе карап, тәҗвид белән укый ала. Алар бик куаналар, мәгънәсен дә белик дип, гарәп телен өйрәнәләр. Ә Корьәндә шундый аятьләр бар, матурлыгына, дөреслегенә ис китеп, шатлыктан елыйсы килә. Мине куандырган шундый аятьләрнең берсе: "Иннә әкрамәкем гиное Ллаһи эткакум", Мәгънәсе: Аллаһу Тәгалә бу дөньяда кем булуыңа карамый, ахирәттә иң хөрмәтле кеше, Аңа буйсынып яшәүче кеше була (ягъни бу дөньяда син бай булмасаң да, этеп-төртеп йөртсәләр дә, Ахирәттә, Аллаһ кушканча яшәгән булсаң, үзеңә тиешле хөрмәтне алачаксың, диелә. Иншә, Аллаһ).

Дөнья җиңел түгел, гаделлек табу да кыен. Шушындый аятьләрне укыгач, ничек шатланмыйсың, ничек: "Әй, Раббым! Ярый әле син бар", - димисең. Күңел йомшарып, Аллаһудан яхшылык сорарга уйлаганда, үз ана телебездә сорарга да ярый. Бер-ике дога рәвешен китереп китәм:

1. И, Раббым! Гафу ителмәгән гөнаһларымны калдырма, җан тынычсызлыгыннан, хәсрәттән коткар! Син риза булырлык бер генә догамны, соравымны да җавапсыз калдырма!

2. И, Аллаһым! Синнән Үзеңнең рәхмәтеңә мине якынайтуыңны сорыйм, мине Үзеңнең ярлыкавыңна илтә торган юлга сал!

Барыбызга да Аллаһудан хәерле гомер, тулы иман сорап

**Гәлимә ХАКИМОВА,**
**мөгаллимә, хаҗия.**